ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.05.2024 г. Заинск № 287

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 августындагы 1343 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль Законга, «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 августындагы 1343 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктында "Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары белән" сүзләрен “Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары белән" сүзләренә алыштырырга.

1.2. 3.9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт хезмәте һәм Россия Федерациясе субъектлары вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук "Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы була алмаган башка затлар керә алмый».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Васильева Е.А.
3-31-00